**СОВЕТ**
**АРХАНГЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423182, РТ, Новошешминский район,
село Слобода Архангельская,
улица Горького, 21а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АРХАНГЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
423182, ТР, Яңа Чишмә районы,
Архангел Бистәсе авылы,
Горький урамы, 21а

тел.: (8-84348) 38-0-40, факс: (8-84348) 38-0-40, Arhan.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Архангел авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 17 нче июнь № 45-149

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 39-129 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»14.11.2023 №39-129 карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче өлешнең 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурыч булу;»;

1.2. 1 нче өлешнең 4 нче пункты карарларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;»;

1.2. Карарның 1 өлеше түбәндәге эчтәлектәге 5 пункт белән тулыландырылырга:

1.3. "5) физик затларда 500 сумнан артмаган бурыч булу, 48 статьяда билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң салым

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында»: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Архангел авыл җирлеге Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Архангел авыл җирлеге башлыгы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Татарстан Республикасы Н.А. Сердюк